**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 5 июнь № 417

г. Казань

Төбәк операторының еллык бухгалтер (финанс) хисаплылыгына аудит үткәрү турында карар кабул итү, аудитор оешмасы (аудитор) белән шартнамәне раслау һәм төбәк операторының еллык хисабын һәм аудитор бәяләмәсен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибен һәм аудитор оешмасын (аудиторны) конкурс нигезендә сайлап алу тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 187 статьясы, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 ел, 25 июнь, 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгәннәрне расларга:

Төбәк операторының еллык бухгалтер (финанс) хисаплылыгына аудит үткәрү турында карар кабул итү, аудитор оешмасы (аудитор) белән шартнамәне раслау һәм төбәк операторының еллык хисабын һәм аудитор бәяләмәсен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибен;

Аудитор оешмасын (аудиторны) конкурс нигезендә сайлап алу тәртибен.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\417.docx